# ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ

## САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

ДҮРТ ТОМДА

4 том

*Иҗат портретлары, публицистик мәкаләләр*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2015

УДК 821.512.145-4
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Ә11

Редколлегия:
*А. Т. Әйделдинов, Р. И. Вәлиев, А. Р. Зарипов,
Д. Ф. Заһидуллина, Р. З. Закиров, К. М. Миңнуллин,
И. К. Сәгъдәтшин*

Төзүчеләре:
*Т. Н. Галиуллин, Р. Г. Галиуллин*

**Әйди, Т. Р.**

Ә11 Сайланма әсәрләр : 4 томда / Тәүфикъ Әйди. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2015.
ISBN 978-5-298-02987-2
4 т. : иҗат портретлары, публицистик мәкаләләр / төз.: Тәлгат Галиуллин, Рөстәм Галиуллин. — 2015. — 510 б.
ISBN 978-5-298-02991-9

Танылган язучы Тәүфикъ Әйди әсәрләренең бу томына, нигездә, Татарстаннан читтә туып үскән һәм танылу алган күренекле милләттәшләребез хакында язылган иҗат портретлары, публицистик мәкаләләре һәм әдипнең үзе турындагы язмалар туплап бирелде.

УДК 821.512.145-4
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-02991-9 (4 т.)
ISBN 978-5-298-02987-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2015
© Галиуллин Т. Н., Галиуллин Р. Г., төзү, 2015

# ИҖАТ ПОРТРЕТЛАРЫ

## НИНДИ МАТУР СИН, ДӨНЬЯ!

«Күрү һәм аңлау шатлыгы —
табигатьнең иң гүзәл бүләге.

*А. Эйнштейн*

Зифа буйлы, алсу битле, кыйгач кашлы, озын керфекле гаҗәеп чибәр кыз иде ул. Аны бүлмәгә ияртеп кергән хәрби киемле ир әле өченче генә елын эшләүче доктор Габдулланың игътибарын башта бик ипле сөйләшүе белән җәлеп итте, шуннан соң аны көтелмәгән тәкъдиме белән шаккатырды:

— Сөлек кебек аргамагым бар. Әгәр кызымны күзле итсәгез, шул асыл мал сезнеке булыр!

Габдулла елмайды, әмма каршы төшмәде, бары тик:

— Бер дә күрмимени? — дип кенә сорап куйды.

— Ике айлык бәби чагында сукырайды. Яктыны тоя, әмма шуннан арысын...

Ир-егетләрне сокландыру, бер гаиләнең учак җылысын саклау, тупылдатып балалар сөю; Урал буеның челтер чишмәләреннән су ташу, алтын кырларында урак уру, күгелҗем тау сыртларына карап хозурлану бәхетеннән рәхимсез язмыш мәхрүм иткән аны. Ата кешенең гозерле карашы, китек күңелле кызның барлык өмете менә шуңа күрә хәзер бары тик табибта гына иде.

Габдулла сылуның күзләрен җентекләп карады, сорашты һәм шулай сукыраю сәбәпләрен ачыкларга тырышты. Аннары, савыктыру өчен, хирургик ысулны сайлап алды һәм бөтен осталыгын җигеп эшкә кереште. Ниһаять, бәйләвечне чишеп алыр көн дә җитте. Ул әле тәмам ныгып җитмәгән күзләрне яктыга акрын-акрын гына күнектерде һәм, ярдәме нәтиҗә бирүенә ышангач кына, кояш нурлары уйнаган бүлмәгә алып керде. Монда әле бер, әле икенче әйбергә төртеп күрсәтеп, кыздан:

— Моны күрәсеңме? — дип сорады.

— Күрәм.

— Нәрсә бу?

Кыз дәшмәде. Бүлмәгә кергән әтисен дә танымагач, Габ-

дулла икеләнә калды, әмма бу кызның беренче тапкыр күргән нәрсәсен атарга кыенсынып торуы гына иде. Аңа бөтен нәрсә белән егерме яшендә өр-яңадан танышырга туры килә иде.

Дәвалау төркеме белән Учалыга килгән Габдулла Ходаяров, Уфага кайтырга җыенган чагында, әлеге кызның атасын тәмам оныткан иде инде. Чөнки аңа Урал аръягындагы бу төбәктә күп кенә авыруларны карарга, байтак операцияләр ясарга туры килде, әмма абзый вәгъдәле кеше булып чыкты — нәкъ юлга кузгаласы көнне генә капка төбенә елкылдап торган алмачуар аргамагын китереп бәйләде. Яшь табиб аптырап калды, эти кешене болай юмартланмаска өндәп, түләүсез дәвалавын аңлатырга тырышты, хезмәтенең алай зурдан булмавын, мондый бүләккә лаек түгеллеген әйтеп саубуллаша башлады. Ләкин абзыйның үз сүзе сүз иде!

— Күз, бәләкәй генә булса да, бөтен дөньяны күрә. Ишеткән — имеш, күргән — көмеш, диләр. Күргәнең көмеш булса, үз күзләрең — асылташ! Алмасагыз бәхил түгел...

— Соң, ничек алып китим мин аны?

— Уфага үзем илтеп куям!

Күрер күзнең кадере сукыр янында арта. Ата кеше ихтирамын, рәхмәтен башкача белдерергә һич тә теләмәде. Габдулла, Пермь университетының медицина факультетын тәмамлап Уфага кайтканнан соң, күз дәваларга алынуына менә шул көнне беренче мәртәбә чын-чынлап сөенде, әлбәттә, бүләк түгел, шатлыгы эченә сыймаган абзый үзе рухландырды аны.

Ул вакытта, дөресен әйтергә кирәк, хирурглар дан тотканлыктан, «яңа пешеп чыккан» табиб сәламәтлек саклау халык комиссарының: «Кайсы белгечлекне сайладыгыз?» — дигән соравына: «Хирург», — дип кенә җавап биргән иде. Комиссар Габдулланың сүзләренә әллә ни әһәмият итмәгән шикелле генә:

— Мин сезне профессор Виктор Петрович Одинцов белән таныштырыйм әле, Мәскәү университетының күз авырулары кафедрасы мөдире белән, — диде. — Заманында ул революцион эше өчен Уфа губернасына сөрелгән, югары белемне Мюнхенга китеп алырга мәҗбүр булган, үзе промышленник улы, шулай да, чит илдә чакта Ленин белән танышып, Россиягә «Искра» ташып йөргән. Бик кызык кеше.

Каникулларда җәен дә, кышын да Уфага килеп, күз авырулары буенча киңәш-табыш биреп йөргән Одинцов үз тармагы өчен милли кадрлар әзерләүгә ихлас ярдәм кулы суза.

— Республикагызда гына да 400 меңләп кешегә трахома йоккан, — ди ул. — Әле бүтән чирләрдән интегүчеләр күпме. Шуларны дәвалаудан да изгерәк эш бармы икән? Бер дә икеләнмичә җиң сызганып тотыныгыз. Мондый җаваплы хезмәткә нәкъ менә сезнең шикелле яшьләр кирәк.

Габдулла шулай кинәт кенә ниятен үзгәртә дә Одинцовның ординаторына әйләнә, аннары Казан университетына аспирантурага китеп бара.

Күз авырулары гыйлеме — офтальмология — медицинада яшь тармакларның берсе. Ул XVII гасырда гына барлыкка килеп, XVIII гасырга кадәр хирурглар карамагында була. XIX йөздә генә махсус күз дәвалау хастаханәләре эшли башлый, офтальмолог врачлар барлыкка килә. Әмма, 1851 елда махсус көзге уйлап табылганчы, алар күзнең тышындагы чирләрне тикшерү белән генә шөгыльләнә. Гасыр ахырында, бактериология фәне үсеше нәтиҗәсендә йогышлы күз авырулары табигате ачыклана башлагач, докторлар җитдирәк уңышларга ирешә, Габдулланың университет тәмамлаган һәм врач эшчәнлеге башланган 1926 елда инде бу өлкәдә өйрәнерлек гыйлем дә, тәҗрибә дә байтак тупланган була. Ходаяров, бөтен күңелен салып, әнә шуларны үзләштерергә керешә.

Ходаяровлар хәзерге Башкортстанның Чакмагыш районы Аблай авылына кайчандыр Пенза якларыннан килеп төпләнгән. Аң-белемгә мәхәббәте бик олы булса да, үз кул көче белән көн күргән Хәбир ага 1899 елда туган улы Габдулланы әллә нинди дәрәҗәле мәктәпкә җибәрә алмый, авылда Енгалычевлар ачкан мәдрәсәгә генә укырга кертә. Бу чорда, бәхеткә, җәдитчә уку керә — балалар дөньяви фәннәр белән дә таныша башлый.

Габдулла, мәдрәсәдә 3 ел укыганнан соң, Аблай авылында 4 класслы училищега керә һәм аны 3 елда тәмамлый. Аннары Уфага педагогик курсларга китә. Революциядән соң мөгаллимнәр семинариясенә әйләнгән бу курсларның дәрәҗәсе бик югары була. Анда укучыларның өчтән икесен — татарлар, калганын үзбәк, төрекмән, кыргыз, казах һәм башка милләт вәкилләре тәшкил итә. Монда алган белем Габдуллага 1920 елда Пермь университетына керергә мөмкинлек бирә.

1913 елда Уфа губернасында 52 мең кешегә — бер врач участогы, стационарда 3500 кешегә бер урын туры килә. Татарларга медицина хезмәте күрсәтү исә тагын да начаррак була. Менә шуңа күрә Габдулла врачлыкка укырга хыяллана.